КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 28 сентябрь г.Казань № 1041

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Татарстан Республикасының Чистай муниципаль районында «Казан – Оренбург» – Кубас – Байтирәк төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегендәге 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында «Иске Матак –Оренбург» – Кубас – Байтирәк автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Кубас авыл җирлеге адресы буенча урнашкан, «Родник» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – алына торган җир кишәрлеге милекчесе) милкендә булган, 444 кв.метр мәйданлы, 16:42:070602:113 кадастр номерлы җир кишәрлеген (алга таба – алына торган җир кишәрлеге) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районындагы Кубас авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлеге милекчесенә, «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен түләү күләме билгеләнгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлеге милекчесенә җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен акча түләүне;

алына торган җир кишәрлегенә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган җир кишәрлеге милекчесе тарафыннан имза куелган килешү законнар белән билгеләнгән срокта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъвалар бирүне.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин